**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1022

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2013 ел, 15 февраль, 104 нче карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2013 ел, 15 февраль, 104 нче карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына, аңарга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Казан шәһәре, Бауман/Профсоюз урамы адресы буенча урнашкан «Икмәк базары, XVII гасыр ахыры – XIX гасыр башы, архитекторы В.И.Кафтырев. Комплекс» җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә җир кишәрлегеннән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре: мәдәният объектлары, сәүдә үзәкләре, эшлекле идарә итү, көнкүреш һәм социаль хезмәт күрсәтү, мәгариф һәм агарту, фәнни эшчәнлек, кибетләр, инженер-техника корылмалары.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1022.docx